# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«29» июнь 2023 ел №32/1

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 январендәге 1/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы», «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 январендагы 1-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 3 февралендәге 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге уставы нигезендә Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 январендәге 1/2 номерлы карары (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының 2020 елның 22 маендагы 3/3, 2022 елның 16 маендагы 22/1 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) нигезендә расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 8.22 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.22. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында мәгълүмат муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә һәм хезмәт кенәгәсенә (булган очракта) кертелә.»;

2) 13 статьяның 13.8 пунктында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 15 статьяда:

15.3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» (алга таба – Татарстан Республикасы Рәисе) сүзләренә алыштырырга;

15.8 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга;

15.9 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга;

15.10 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга;

15.11 пунктында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алыштырырга;

15.13 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга;

15.14 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга;

4) 18 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 18.6 пунктын өстәргә:

«18.6. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы арасында кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында килешү нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча бердәм конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.»;

5) 19 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 19.7 пунктын өстәргә:

«19.7. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы арасында кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында килешү нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының бердәм аттестация комиссиясе тарафыннан үткәрелә.»;

6) 20 статьяның 20.1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 20.1 пунктын өстәргә:

«5) муниципаль хезмәткәрләрнең чит ил агенты статусын алулары.»;

7) 28 статьяның 28.3 пунктына «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

8) 29.3 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе (алга таба – хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе) яки «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты хакимиятенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;»;

9) 29 статьяның 29.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29.9. Әлеге Нигезләмәнең 12, 14 һәм 26 статьяларында каралган җәзалар муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциячел хокук бозу кылулары турында мәгълүмат килгән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсезлеге, ялда булу вакыты чорын исәпкә алмыйча, һәм коррупциячел хокук бозу кылынган көннән алып өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларга җинаять эше буенча эш вакыты кертелми.»;

10) 31 статьяның 31.11 пункты 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән мәгълүматлар һәм (яки) хезмәт кенәгәсе күчермәсе яки гражданның хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт эшчәнлеге элек гамәлгә ашырылмаган очраклардан тыш);».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгәннән) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Р.М. Дусадбеков